ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь, 2016 ел № 11/12

Шәһәр Советының 2012 елның 26 январендәге 16/9 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маендагы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 26-ЗРТ санлы Законы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2012 елның 26 январендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм аның бүлекләре карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составларын раслау турында» 16/9 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2012 елның 5 июлендәге 19/14, 2013 елның 30 маендагы 25/17, 2013 елның 30 октябрендәге 27/17, 2014 елның 17 апрелендәге 30/17, 2014 елның 10 июлендәге 31/21, 2015 елның 27 февралендәге 38/10, 2015 елның 15 апрелендәге 39/20, 2015 елның 17 декабрендәге 4/11, 2016 елның 7 апрелендәге 7/12, 2016 елның 17 августындагы 10/6 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Үзәк районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия бүлеге составына кертергә:

- Гаянова Лилия Зиннур кызын – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең әйдәүче белгечен;

комиссия бүлеге составыннан чыгарырга:

- Богданов Илгиз Илдар улын;
- Ибраһимова Лилия Илсур кызын;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия бүлеге составында:

- Баринова Елена Сергеевнаның вазифасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе 1 нче «Автозавод» полиция бүлегенең балигъ булмаганнар эше буенча бүлекчә башлыгы;

комиссия составына кертергә:

Галимов Айдар Искәдәр улын – Россия җәзаларны башкару федарль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе башлыгын (килешү буенча);

Харисова Лилия Рафаил кызын – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Автозавод районы хакимиятенең халыкка социаль ярдәм бүлеге әйдәүче белгечен;

Мингазова Лилия Мансур кызын – Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе 3 нче «Үзәк» полиция бүлегенең балигъ булмаганнар эше буенча бүлекчә инспекторын;

комиссия бүлеге составыннан чыгарырга:

- Николаева Надежда Григорьевнаны;
- Кузахметова Наталья Викторовнаны;
- Шәйхәдарова Чулпан Рәшид кызын;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Комсомол районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия бүлеге составына кертергә:

- Шәймәрданова Светлана Генадьевнаны – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Комсомол районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең әйдәүче белгечен;

комиссия бүлеге составыннан чыгарырга:

- Галимуллина Рузия Ринат кызын;
- Айдимирова Ольга Викторовнаны;
- Тарнаева Ольга Николаевнаны.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ